КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 6

«Рубин» футбол клубы» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсенә Татарстан Республикасы вәкилен билгеләү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында Татарстан Республикасы вәкилләре катнашу тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 июнь, 466 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Рубин» футбол клубы» автоном коммерциягә карамаган оешмасы идарәсенә Татарстан Республикасы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Хәмит улы Гафаровны билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин